РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, д.38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423950, Урыссу ш.т.б., Пушкин урамы, 38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 17 » 03 2022 г. №187

2022 елга гаиләнең һәр әгъзасына
яисә ялгыз яшәүче гражданга туры
килә торган керемнең һәм гаилә
әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан
милкендә булган һәм салым салынырга
тиешле мөлкәт хакының иң чик күләмнәрен
билгеләү турында

Россия Федерациясе Торак кодексы, 2015 елның 16 мартындагы 13-ТРЗ номерлы «Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы башкарма комитетының 02.03. 2022 ел, №129 номерлы «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы буенча торак мәйданының 1 квадрат метрының уртача базар хакын 2022 елның 1 кварталына раслау турында» карары нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендә булган һәм 2022 елга салым салынырга тиешле мөлкәт хакының һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм мөлкәт хакының иң чик күләмнәрен билгеләү методикасы буенча «Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннары наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2015 елның 16 мартындагы 13-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән расланган 2022 елга гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм мөлкәт хакының түбәндәге иң чик күләмнәрен билгеләргә (1 нче кушымта).

2.Инфраструктура үсеше бүлеге начальнигы урынбасарына социаль файдаланудагы торак урыннарына мохтаҗлар буларак гражданнарны исәпкә

куйганда 1 нче кушымтада күрсәтелгән керемнең максималь күләмен файдаланырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасының Ютазы муниципаль районы сайтында «Рәсми Татарстан» дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм Порталы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе С.П. Самонина

Н.А. Әбилтарова
2-76-81

1 нче номерлы кушымта
Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитетының
17.03.2022 ел, №187
карарына

**Һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм 2022 елга салым салынырга тиешле мөлкәт хакының чик күрсәткечләре**

| Гаилә әгъзалары саны (РС) | Торак урын бирү нормасы буенча базар бәясенең исәп күрсәткече (СЖ) | Һәр гаилә әгъзасына туры килә торган уртача айлык керемнең чик күрсәткече |
|---|---|---|
| 1 | 514 278 | 13 799 |
| 2 | 1 028 556 | 13 799,4 |
| 3 | 1 542 834 | 13 799,6 |
| 4 | 2 057 112 | 13 799,6 |
| 5 | 2 571 390 | 13 799,6 |
| 6 | 3 085 668 | 13 799,6 |
| 7 | 3 599 946 | 13 799,6 |
| 8 | 4 114 224 | 13 799,6 |
| 9 | 4 628 502 | 13 799,6 |
| 10 | 5 142 780 | 13 799,6 |